РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

06.03.2020

№ 382-п

Саба муниципаль районында инвалидлар өчен мәгариф өлкәсендәге объектлар һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алырлык шартларны тәэмин итү, шулай ук аларга бу очракта кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының “Инвалидлар өчен мәгариф өлкәсендәге объектлар һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алырлык шартларны тәэмин итү, шулай ук аларга бу очракта кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында” 2015 елның 9 ноябрендәге 1309 номерлы боерыгын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында инвалидлар өчен мәгариф өлкәсендәге объектлар һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алырлык шартларны тәэмин итү, шулай ук аларга бу очракта кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә инвалидларның социаль инфраструктура объектларына тоткарлыксыз үтеп керүе өчен шартлар тудыруны тулы күләмдә тәэмин итәргә.

3. Белем бирү учреждениесенә керүне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып тулысынча җайлаштыру мөмкин булмаса, инвалидларга белем бирү учреждениесенә алар белән бер бинада урнашкан учреждениеләр ишекләре аша керергә рөхсәт итәргә, ә администрация кабинетларына, методик һәм медицина кабинетларына, бәдрәф бүлмәсенә керүне озата баручы кешене бирү юлы белән тәэмин итәргә.

4. Белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә объект эчендә халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең керү һәм хәрәкәт итү тәртибен регламентлаштыра торган локаль актларга төзәтмәләр кертергә.

5. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мәгариф идарәсе” Муниципаль казна учреждениесенә (алга таба - Мәгариф идарәсе) әлеге карарны Мәгариф идарәсе сайтында урнаштырырга һәм Саба муниципаль районының мәгариф оешмалары җитәкчеләренә җиткерергә.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” Муниципаль казна учреждениесе начальнигы И.Ф. Шакировка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р.Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
____________________
____________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында инвалидлар өчен мәгариф өлкәсендәге объектлар һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алырлык шартларны тәэмин итү, шулай ук аларга бу очракта кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибе**

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләре, закон һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә, инвалидларга белем бирү оешмаларына керү өчен түбәндәге шартларны тудыралар һәм алар белән тәэмин итәләр:

– объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

– хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтүче объект хезмәткәрләре ярдәмендә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

– объектка керү алдыннан, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, объект хезмәткәрләре ярдәме белән, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

– күрү функциясе нык бозылган инвалидларны озата бару һәм объект хезмәткәрләре ярдәмендә объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

– инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында объект хезмәткәрләре ярдәмендә хәбәр итү;

– инвалидларга алар файдалана алырлык формада хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү, алар тарафыннан хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләр кылу турында мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

– мәгариф оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга мәгариф өлкәсендә хезмәт алырга һәм объектларны башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү;

– инвалидларның объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны йөртүчеләрне, аларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, тиешенчә урнаштыру, шул исәптән хезмәт алу өчен тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язулар, билгеләр һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-ноктталы шрифты һәм контраст фонында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

– Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының

“Озатучы этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында” 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча бирелгән махсус укытуны раслый торган документ булганда, хезмәтләр күрсәтелә торган объектка яисә хезмәт күрсәтү урынына озатучы этнең керүен тәэмин итү;

– инвалидлар өчен объектлар һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең файдалана алырлык булу дәрәҗәсен этаплап күтәрү чараларын билгеләү максатларында, әлеге объектларга һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә тикшерү уздырыла, аның нәтиҗәләре буенча инвалидларның объект һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуы паспорты төзелә (алга таба - тикшерү һәм паспортлаштыру, һәркем файдалана алырлык Паспорт).

– тикшерү үткәрү һәм паспортлаштыру өчен мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче органның яисә оешманың күрсәтмә акты белән объектка һәм анда күрсәтелә торган хезмәтләргә тткшерү үткәрү һәм аларны паспортлаштыру буенча комиссия (алга таба - Комиссия) төзелә, аның составы, тикшерү һәм паспортлаштыруны үткәрүнең план-графигы раслана, шулай ук Комиссия эше оештырыла.